| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.12.2025 № 1448

Бала (балалар) туганда бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында туучылар санын арттыру, демографик вәзгыятьне яхшырту һәм халык саны кимүнең тискәре тенденцияләрен җиңеп чыгу чараларын көчәйтү максатларында

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә даими яшәү урыны буенча теркәлгән хатын - кызларга беренче, дүртенче һәм аннан соңгы һәр бала туганда өстәмә социаль ярдәм чарасы-10 000 (ун мең) сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә даими яшәү урыны буенча теркәлгән хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
3. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карар белән билгеләнгән өстәмә социаль ярдәм чарасын күрсәтүне җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслауны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин